# МАЯК

Чәршәмбе 28 октябрь 2015

tatmedia.ru aznakaevo-rt.ru

Азнакай муниципаль районы газетасы

Газета 1930 елдан чыга

№79 (12980)


КҮҢЕЛЛЕ ХӘБӘР

# АЗНАКАЙ ТАГЫН ДА ЧИСТАРАЧАК



Марат Гәрәев машинаны «олы» юлга чыгарырга әзерли

## Нефтьчеләрнең чираттагы бүләге

Бүген районыбыз үсешен нефтьчеләребез ярдәменнән башка күз алдына да китереп булмый. Кайсы гына тармакны яки өлкәне алсаң да, аларның саллы ярдәмен тоясың. Шушы көннәрдә “Татнефть” җәмгыяте безгә чираттагы олы бүләген ясады: шәһәргә вакуум-себерү машинасы (халык телендә – тузан суырткыч) һәм район-шәһәр Мәдәният йортына, Яшьләр үзәгенә, Актүбә бистәсенең Гагарин исемендәге мәдәният йортына музыкаль аппаратуралар бүләк итте. Машина ачкычын һәм аппаратура алуга сертификатларны дүшәмбе киңәшмәсендә муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллинга “Азнакайнефть” идарәсе җитәкчесе урынбасары Наил Вәлиев тапшырды.

–“Азнакайнефть” идарәсенең 60 еллыгы уңаеннан җирлегебезгә әзерләнгән бүләкләрнең берничәсе генә әле бу. Алга таба да халыкка уңайлы мохит тудыру юнәлешендә бик күп эшләр башкарылачак, – диде үзенең чыгышында Наил Вәлиев.

Район башлыгы исә күптән хыялланган, иң мөһиме, бик кирәкле һәм кадерле бүләкләр өчен “Татнефть” җәмгыяте һәм “Азнакайнефть” идарәсе җитәкчелегенә ихлас рәхмәтләрен җиткерде.

Бүген себерү-вакуум машинасы шәһәр урамнарын чистартуга чыгар өчен соңгы тикшерүләрне уза.

– Моңа кадәр юлларны тузан-туфрактан арындыру кул хезмәте белән башкарылды. Мондый махсус машина булгач, шәһәр урамнары тагын да чистарак булыр, – ди Яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча күптармаклы җитештерү предприятиесенең база җитәкчесе Рифмир Вәлитов. – Ләкин матурлыкның чисталыктан башланганын истән чыгармаска иде. Кызганыч, кешеләр әле дә “Чисталык җыештырган җирдә түгел, ә чүпләмәгән җирдә” дигән гыйбарәнең асылына төшенеп җитә алмый.

Әйе, барыбыз бердәм булып, урамнардагы чисталык өчен бергә көрәшкәндә генә Азнакаебыз шулай балкып торыр. Шунсын да истә тотарга кирәк, без бит әле Татарстан Республикасының иң төзек шәһәрләреннән берсе дә!


Мондый тикшерүләр үз нәтиҗәсен бирми калмас

## Сулар һавабыз чиста булсын!

Узган атнада ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Ык буе территориаль идарәсе “Газель” автомобиле базасында урнашкан күчмә экологик лаборатория белән тулыланды. Машина ачкычын идарә җитәкчесе Хәлил Мөстәкыймовка Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе тапшырды. Ул һаваны пычрата торган зарарлы матдәләрнең, әйтик, аммиак, күкертле водород, азот оксиды һәм башкаларның булу-булмавына экспресс анализ үткәрү өчен каралган.

– Әлегә кадәр без һава анализын урынга чыгып, аны махсус пробиркаларда алып кайтып, идарәдә урнашкан лабораториядә ясый идек. Хәзер исә күрсәткечләрне алу, тикшерү онлайн режимда башкарыла. Бу табигатьне саклау өлкәсендәге закон бозу очракларын оператив рәвештә ачыкларга мөмкинлек булдырылачак дигән сүз. Лабораториядә алып барылган барлык тикшерүләр дә автомат рәвештә “Татарстан Республикасының экологик картасы” геоинформация системасына китеп бара, – ди махсус аналитик күзәтү үзәге инспекциясе начальнигы Айгөл Ярмиева. – Күчмә лаборатория ярдәмендә җил юнәлешен, аның тизлеген, атмосфера басымын һәм һава дымлылыгын да билгеләп була.

### СҮЗ УҢАЕННАН

Хәзерге вакытта мондый күчмә лабораторияләр Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә генә бар. Безгә бирелгән лаборатория Баулы, Мөслим, Ютазы районнарына да хезмәт күрсәтәчәк

---

Көнегезне «Маяк»ның ***aznakaevo-rt.ru*** сайтыннан – иң соңгы хәбәрләр белән танышудан башлагыз

### НӘРСӘ. КАЙДА. КАЙЧАН

Туган төбәгебезнең үсешендә төзүчеләрнең дә тырыш хезмәте ята. Узган җомгада Мәдәният йортында әлеге тармак ияләрен хөрмәтләделәр. Муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллин районыбыз төзелешенә өлеш керткән ветераннарга, бүгенге көндә аларның эшен лаеклы дәвам итүчеләргә тирән рәхмәтен белдереп, бүләкләр тапшырды. Тантаналы чара татар эстрадасы йолдызларының концерты белән үрелеп барды.

Өлкәннәр айлыгында һәр оешма-предприятие алдына үз ветераннарына мөмкинлектән чыгып матди ярдәм күрсәтү бурычы куелды. Ә инде бюджет өлкәсе, предприятиеләре ябылган һәм районга күчеп килгән 70тән өстәге ветераннарыбызга, барсы 2350 кешегә, ул башка чыганаклардан алынды. Шул рәвешле, айлык барышында районда 7291 өлкән кешегә, барсы 3 миллион 800 мең сумлык матди ярдәм күрсәтелде.

Мәгариф хезмәткәрләре алдына белем бирүнең сыйфатын күтәрү бурычы куелды. Җиңү бистәсе мәктәбе базасында узган математика һәм башлангыч сыйныф укытучыларының район семинарында да бу мәсьәлә көн үзәгендә булды. Анда катнашучылар 1,4, 5 нче сыйныфларда математика дәресләрендә булдылар, федераль дәүләт белем бирү стандартларының ничек тормышка ашырылуы белән таныштылар, укучылар башлангычтан төп звенога күчкәндә сыйфат күрсәткечләрен киметмәү мәсьәләләре хакында фикер алыштылар.

Бүгенге кибет киштәләрендәге муллыкка күзләр камаша һәм еш кына без ризыкның файдалымы-зыянлымы икәнен уйламыйча да, кабина яки рекламасына алданып сатып алабыз. Бигрәк тә балаларга аңлатуы кыен. Туган төбәкне өйрәнү музее хезмәткәрләре Халыкара азык-төлек көне уңаеннан бик файдалы чара оештырып, балаларга кибеттән азык-төлек алганда нәрсәләргә игътибар итәргә кирәклеге турында киңәшләрен бирделәр.

Кайбер тарихи мәгълүматларны хәзерге чордагылар белән чагыштырганда, кызыклы фактларга юлыгасың. Әйтик, узган гасырның 80-90нчы елларында җирлегебезнең авыл хуҗалыгы өлкәсендә 10,5 мең эшче кул исәпләнсә, хәзер аларның саны 2 мең чамасы. Ә бит югыйсә сөрүлек җирләр дә, мал-туар саны да шул ук дәрәҗәдә диярлек калды. “Шунлыктан, авылларда, шәһәрдә яшәүче өлкәннәребез кайбер урыннарда күпвакыт төп эшче көч булып кала да, ә инде язгы-көзге кыр эшләре чорында булдыра алган һәркайсыбыз ярдәм итәргә тырыша”, – ди ветераннар советы рәисе Миргасим Кәримов.

Тестлар укучылар өчен генә түгел, укытучылар өчен дә үткәрелә. Шушы көннәрдә мәгариф идарәсенең мәгълүматиметодик бүлегендә квалификация дәрәҗәсен билгеләп, аттестация үтәргә теләгән педагоглар тестлаштыру узды. Ул off-line режимында барды. Анда барлыгы 105 педагог квалификация дәрәҗәсен тикшерде.

## Депутат кабул итә

Октябрь аенда “Бердәм Россия” партиясенең Азнакай җирле бүлегендә (Солтангалиев ур., 21, Мәдәният йортының 1 нче каты) ТР Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Мөхәммәдиев район халкы белән очрашачак. 7-01-92 телефоны буенча депутат кабул итүенә алдан язылырга мөмкин.

# КИЧӘ. БҮГЕН. ИРТӘГӘ

ТӘҖРИБӘ

## МЕКСИКАННАР АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА ЯҢА ПРОЕКТ ТӘКЪДИМ ИТТЕ

**Татарстанда тотрыклы үсеш алган районнарның берсе буларак, чит төбәкләр һәм илләрнең Азнакай белән кызыксынуы арта бара.**



Төркия, Белоруссия, Кырым белән багланышлар матур гына дәвам итә. Быел җәен итальяннар эшлекле визит ясаган иде. Шушы көннәрдә муниципаль район башлыгы Марсель Шәйдуллин Мексика компаниясе вәкилен кабул итте. Очрашуда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы урынбасары Тәлгать Хафизов, район эшмәкәрләр берлеге рәисе Әнвәр Җиһангиров, крестьян-фермер хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Айрат Габдрахманов та катнашты.

Агросәнәгать өлкәсендә консультант Хосе Луис Гомес Родригес туфракның уңдырышлылыгын күтәрүче нәтиҗәле технологияләр белән таныштырды. Аны пилот проекты буларак тәкъдим итүче як хисабына Татарстанның дүрт районында тормышка ашырырга ниятлиләр. Марсель Шәйдуллин проектта катнашырга ризалыгын белдерде. Бу язда ук тәҗрибә участогы био-көчәйткечләр белән тукландырылачак. Хосе Луис Гомес Родригес сүзләренә караганда, әлеге продукт туфракны ашламалар һәм пестицидлардан арындырып, туклыклы матдәләрне кире кайтара, каткан катламны йомшарта, уңышны 30 процентка арттыра.

**Резеда ШӘРИПОВА**

РӘСМИ

## Сайлаучылар игътибарына!

2015 елның 30 октябрендә Азнакай шәһәр Советы депутатлары сайлау округлары үзәкләрендә үзләренең сайлаучыларын кабул итәләр.

Азнакай район Советы депутатлары халыкны җирлекләрнең административ үзәкләрендә кабул итә.

Сайлаучыларны кабул итү вакыты: 16.00-17.00 сәгатьләрдә

Тулырак мәгълүмат белән Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (aznakayevo.tatarstan.ru) "Район турында. Җирле үзидарә органнары. Депутатлар" бүлегендә танышырга була.

| Сайлау округы | Сайлау округы үзәге | Депутат | Телефоннар |
|---|---|---|---|
| 1 нче сайлау округы | 9 нчы мәктәп, Лениногорск тракты., 2а йорт | Гайсин Марат Салих улы, | 9-43-34<br>9-44-97 кабул итү бүлмәсе |
| 2 нче сайлау округы | 9 нчы мәктәп, Лениногорск тракты., 2а йорт | Шәрәфиев Айдар Әдип улы | 9-39-84<br>9-30-66 |
| 3 нче сайлау округы | 1 нче мәктәп (иске бина), Мәктәп ур., 2 нче йорт | Рябченко Олег Алексеевич | 54-1-91<br>54-116 |
| 4 нче сайлау округы | "Азнакай шәһәре гимназиясе", Ленин ур., 1 нче йорт | Вәлиев Азат Идрис улы | 5-11-25<br>5-10-10<br>5-11-21 |
| 5 нче сайлау округы | 3 нче мәктәп, Пушкин ур., 1 нче йорт | Хәсәнов Рәфис Кәбир улы | 58-003<br>5-31-98 |
| 6 нчы сайлау округы | Балалар иҗаты үзәге, Ленин ур., 18 нче йорт | Миңнекаев Равил Арнис улы | 5-15-70<br>55-0-25 |
| 7 нче сайлау округы | 2 нче мәктәп, Болгар ур, 18 нче йорт | Мөгътәсимов Руслан Рөстәм улы | 7-35-65 |
| 8 нче сайлау округы | "Алтын алка" боз сарае, Солтангалиев ур., 21а йорт | Садыйков Азат Рамил улы | 5-11-38 |
| 9 нчы сайлау округы | "Дельфин" физкультура-сәламәтләндерү үзәге, Солтангалиев ур., 23а йорт | Хуҗин Рашат Мөҗәһит улы | 7-40-14 |
| 10 нчы сайлау округы | 8 нче мәктәп, Хәсәнов ур., 19 нчы йорт | Измайлов Рамил Хәкимҗан улы | 51-7-36<br>51-7-33 |
| 11 нче сайлау округы | 4 нче лицей, Хәсәнов ур., 5 нче йорт | Дәүләтшин Рөстәм Ибраһим улы | 7-79-74 |
| 12 нче сайлау округы | 4 нче лицей, Хәсәнов ур., 5 нче йорт | Мирмиев Азат Малик улы | 9-45-60<br>9-38-34 |
| 13 нче сайлау округы | 5 нче мәктәп, Ленин ур., 3б йорт | Солтанов Марат Инсаф улы | 7-32-26<br>7-41-48 |
| 14 нче сайлау округы | 6 нчы мәктәп, Гагарин ур., 9 нчы йорт | Алчина Элеонора Айрат кызы | 7-28-20<br>8 917 276 -9205 |
| 15 нче сайлау округы | 6 нчы мәктәп, Гагарин ур., 9 нчы йорт | Шакиров Руслан Әсләм улы | 7-15-16 |
| 16 нчы сайлау округы | Азнакай район үзәк сырхауханәсе, Хәсәншина ур., 21 нче йорт | Попов Владимир Александрович | 58-003<br>5-31-98 |
| 17 нче сайлау округы | 7 нче мәктәп, Хәсәнов ур., 24 нче йорт | Вәлиев Наил Альберт улы | 51-2-35.<br>58-1-55<br>58-003 |
| 18 нче сайлау округы | "Лениногорск политехник колледжы" филиалы, Солтангалиев ур., 27 нче йорт | Бәзгытдинов Рөстәм Фәрит улы | 7-74-84<br>7-79-79 |
| 19 нчы сайлау округы | 1 нче мәктәп (яңа бина) Иркен ур., 3 нче йорт | Фәрхуллин Илфат Нургали улы | 9-51-13<br>9-38-43 |
| 20 нче сайлау округы | 1 нче мәктәп (яңа бина) Иркен ур., 3 нче йорт | Шәйдуллин Марсель Зәфәр улы | 7-24-83 |

**Район Советының оештыру бүлеге**

КЫСКАЧА ТӨРЛЕСЕННӘН

### КАРАВЫЛ, КАРАВЫЛЧЫ ЮК!

Көзге чорда табигать йокыга талса да, каракларның бу вакытта "уянуын" истән чыгармасак иде. Караучысыз калган фермалар – караклар өчен менә дигән җим. Агымдагы елның тугыз аенда Тымытык, Уразай, Илбәк авылларындагы фермалардан мал урлау очраклары теркәлгән. Әлеге мәсьәлә дүшәмбе киңәшмәсендә дә күтәрелде.

– Фермаларда каравылчылар, яктылык, коймалар, ныклы һәм ышанычлы бик, рәшәткәләр, элемтә булмау, мал-туар бурларына кыңгыр эшләрен башкарырга аеруча җиңеллек тудыра, – ди район эчке эшләр бүлеге начальнигы Илдар Шакиров.

Бу уңайдан район башлыгы Марсель Шәйдуллин зур канәгатьсезлек белдереп, авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчелегенә барлык фермаларда булып, һәрберсе буенча аерым справка бирүне таләп итте.

– Каравылчыга акча түләмичә, бер баш малны гына урлатып та без никадәр акча югалтабыз?! Саклык чаралары күрү хакында күпме генә сөйләп, әйтеп килсәк тә, ул эш башкарылмый, димәк барлык фермаларга да видеокүзәтү системасын мәҗбүри урнаштырырга кирәк, – диде Марсель Шәйдуллин.

Җирлегебездә физик мөмкинлекләре чикләнгәннәргә уңай мохит тудыру – көн кадагындагы мөһим сорауларның берсе. Бу уңайдан районда максатчан программа да эшли. Программа нигезендә сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләре, кайбер йорт подъездлары һ.б. инвалидлар мәнфәгатен күздә тотып төзекләндерелгән. Әммә проблемалар да юк түгел, бүген тагын 20 подъездга пандуслар төзергә кирәк. Бу җәһәттән район башлыгы пандуслар исем өчен генә ясалган булырга тиеш түгел дип белдерде.

Кайбер пандустан коляска белән түгел, хәтта җәяүләп тә менәрлек түгел. Аны ясаганнар икән, ул таләпләргә туры килергә тиеш дип ассызыклады муниципаль район башлыгы.

Киңәшмә барышында шулай ук диспансерлаштыру, җылылык сезоны, демографик үсеш мәсьәләләре дә күтәрелеп, җитәкчеләргә тиешле күрсәтмәләр бирелде.

### КҮРҮЧЕЛӘР ЮКМЫ?

Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча бүлеге 1996 елгы Садыйкова Эльвира Айзат кызын эзли. Ул Әлкәй авылында яшәгән. 16 сентябрь көнне өеннән чыгып китә, шул көннән алып аның кайдалыгы турында бернинди мәгълүмат та юк.

Билгеләре: буе якынча 155-160 см., ябык гәүдәле, коңгырт-кара күзле, чәче кара төстә. Өстендә кара төстәге куртка, кара гамаш, аягында баулы спорт ботинкалары булган.

Эльвира Садыйкова турында нинди дә булса мәгълүматка ия булган кешеләрнең район эчке эшләр бүлегенә 02 яки 7-30-87 телефон номерлары буенча шалтыратулары сорала. Анонимлык гарантияләнә.

ТЫЛ ФИДАКАРЬЛӘРЕ

# ПАКЪ КҮҢЕЛЛЕ АК ӘБИЛӘР

–Шушы нәфис җилкәләргә гомер буе авыр йөк салган, күпне күргән буын бит сез, – дип Әнисә апаның иңнәренә ак шәл япты район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының икътисад буенча урынбасары Гөлия Сөләйманова. – Бер караңгыдан икенчесенә хезмәт куеп, ачлык-ялангачлыклар кичерсәгез дә, күңелләрегез пакъ, мәрхәмәтле, ихлас булып калган. Бүген төп йортка җыелган шушы балаларыгыз, онык-оныкчыкларыгыз назына төрелеп, җан тынычлыгында, сихәтлектә, бәрәкәттә яшәргә язсын!

Мәлбагыш авылында туып, шушында гомер кичергән Әнисә Мөхәммәтҗанова. Чордашлары кебек аңа да бик иртә колхоз эшләрендә катнашырга туры килгән.

–16шар килолы букчаларны күтәреп, Әлкәй белән ике



арада орлык ташыйбыз. Чабата пычракта тузмасын дип, иртәнге катканакта ук чыгып китәбез, – дип искә ала ул яшьлек елларын. – Сабан да сөрдек, тырмаладык та, 2шәр гектар чөгендер утадык, борчак чаптык...

Ил өчен иң авыр еллар – Бөек Ватан сугышы чоры була ул.

–Җиңү хәбәрен басуда чакта, яңгырдан атларга ышыкланып, бераз хәл алырга тукталганда ишеттек, укытучыбыз килеп әйтте. Шатлануыбызны белсәгез, лычма булып су аккан киемнәребез дә кибеп киткәндәй тоелды, әчкә җылы йөгерде... – ди Әнисә апа күз яшьләрен сөртеп.

Авылдашы, фронтовик егет Солтангир белән гаилә корып, 3 бала үстерә алар. 50 ел бергә гомер иткән ирен югалту ачысы, инде 15 ел үтсә дә, бер кәлимә кимеми, никадәр борчу-хәсрәтләр дә, шатлык-куанычлар да бергә кичерелгән шул!

Лаеклы ялга чыкканчы шактый еллар тавык фермасында эшләгән, тырыш хезмәте өчен күпсанлы Мактау кәгазьләренә, медальләргә лаек булган Әнисә апа ире белән бергә төзеп, 9 кешеле гаиләдән башка чыккан йортларында яшәп ята. Атна ахырында җыйналып балалары, оныклары кайтып җитәләр. Мунча ягыла, өстәл ризыклар белән тула. Бүген, әниләренең 90 яшенә, алар сый-нигъмәтнең ниндиен генә әзерләмәгән. Авылның ак әбисен котларга күрше-тирә җыелган. Авыл биләмәсе башлыгы Эльмира Әхтәмова да бүләкләрен күтәреп килгән, социаль яклау бүлеге вәкилләре дә бар.

Ак шәл ябынган Әнисә апа балалары белән коръән ашына әзерләнеп калды. Тормышыбыз менә шушы ак әбиләр белән ямьле, бүген шулар аркасында рәхәт, бәрәкәтле...

**Лиза НУРЛЫЕВА**

КӨЗГЕ ЧАКЫРЫЛЫШ

# ЕГЕТЛӘР СОЛДАТКА КИТТЕ

23 октябрь көнне Азнакай шәһәренең "Чатыр- Тау арена" спорт комплексында "Призывник көне" узды.



Быел ул аеруча тантаналы шартларда барды: хәрби хезмәткә җыенучы егетләргә хәер-фатиха бирергә район башлыгы Марсель Шәйдуллин, җитәкчеләр белән бергә башкала кунаклары – ветераннарның төбәк җәмәгать оешмасы республика советы рәисе Хәбир Иштирәков, «Татарстан Республикасы сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары комитеты» җәмгать оешмасы рәисе Әхәт Юлашев та килде. Алар егетләрнең ил алдындагы изге бурычларын уңышлы үтәп, исән-имин туган якларга әйләнеп кайтуларын теләделәр.

Һәр елны хәрби-спорт ярышларында көч, җитезлек, осталыкны сынау рәвешендә барган бу чарада зал шаулап-гөрләп торды. Тамашачылар 7 командага дәрт өстәп, һәр чыгышны бик җитди күзәтеп барды. Узган елларда командалар нигездә яшь-җилкенчәктән – призывниклар һәм югары сыйныфларда, көллиятләрдә укучылардан торса, быел аларга әфган сугышы ветераннары һәм төрле елларда Диңгез флотында хезмәт иткән өлкән яшьтәгеләр дә кушылды.

Бу бәйгеләрдә егетләр мылтык сүтеп-җыюда булсынмы, пневматик коралдан ату, көч сынау күнегүләре... – һәммәсендә тәҗрибәле солдатлардан һич калышмый, үзләренең хәрби хезмәткә әзер булуларын дәлилләделәр.

Ярышларны зур кызыксыну белән күзәткән Азнакай егете Рузил Рәшитов белән әңгәмә корып алабыз. Бу көздә ул да армиягә китәргә җыена.

–Морфлотка яки ВДВга эләгергә иде, – ди көч-гайрәте ташып торган, грек-рим көрәше буенча спорт мастеры булган егет. Әләгер, билгеле, мондыйларны да алмасалар! Күренеп тора, кечкенәдән максат куеп, үз өстендә нык эшләгән.

Ә инде дүшәмбе иртәсендә егетләребез юлга да кузгалды.



Быелгы көзге чакырылышның беренче отправкасын, матур гадәткә әверелгәнчә, район җитәкчеләренең атналык киңәшмәсе алдыннан, шәһәрнең Татарстан мәйданында тантаналы итеп озаттылар.

–Бүген ил сагына иң әзерлекле 15 егетебезне озатабыз, – диде район башлыгы Марсель Шәйдуллин. – Менә шундый лачыннар үстергән әти-әниләргә рәхмәтләребезне җиткереп, аларның исән-имин әйләнеп кайтуларын телибез!

Хәрби хезмәткә китүчеләр алдында чыгыш ясаган барсы да изге теләкләрен юллады. Дин әһелләренең догалары да аларны яманлыклардан аралар, саклар, иншаллаһ.

Шундый тантаналарда егетләрне һәр елны дәртле көйләр уйнап озатып калган тынлы оркестр җитәкчесе Иван Сергеевның бу юлы аеруча дулкынлануы сизелә иде. Ул бүген язмыш сабый килештән зур сынаулар алдына куйган оныгын да – Суворов училищесын тәмамлаган Владислав Моисеевны хәрби хезмәткә озата. Бәгыре телгәләнсә дә, сиздерми. Кайчандыр үзе дә ил алдында бурычын үтәгән "карт солдат" буларак, аның тагын да нығып, тормыш тәҗрибәсе туплап, чын ир-егет булып кайтачагын белә ул.

**Лиза НУР**

МӘДӘНИЯТ

# «Ак чәчәкләр» – Азнакайда, азнакайлылар – «Ак чәчәкләр»дә!

Еллар узып та үз аһәңен җуймаган әсәрләр була. Габдрахман Әпсәләмовның "Ак чәчәкләр"е – әнә шундыйлардан. Аның буенча фильм төшерелүе турында күптән экраннар аша яңгыраган иде. Бу шимбәдә азнакайлылар аны тамаша кылу бәхетенә ирештеләр.

Мәдәният йортында алма төшәр урын юк. Мәңгелек темалар – мәхәббәт, намус, вөҗдан турында фильм бер сулышта, тын да алмый каралды. Нечкә күңелләрнең күзләреннән хәтта яшьләр тәгәрәде.

"Ак чәчәкләр" романы җитмешенче елларда телевизион спектакль булып төшерелгән булган. Ул чакта Гөлшаһидә ролен якташыбыз Нәҗибә Ихсанова башкарган. Фильмда ул героинясының олыгайган чорын уйнады. Якташыбыз Әзһәр Шакировны да профессор Таһиров ролендә күрдек. Элекке куелышта ул Мансур ролен уйнаган. Фильмда шулай ук районодашларыбыз Ләйсәнә Садретдинова һәм Рәмзия Закирҗанованың катнашуы да зур горурлык уятты.

– Үзем дә һөнәрем буенча табиб буларак, бу фильмны бик дулкынланып карадым. Моннан ярты гасыр элек язылса да, темасы бүген дә бик актуаль, – диде район башкарма комитеты җитәкчесе Айдар Шәмсетдинов.

Ул очрашуга кайткан артистлар Нәҗибә Ихсанова, Ләйсәнә Садретдинова, Рәмзия Закирҗанова һәм Гөлназ Галимуллинага азнакайлылар исеменнән рәхмәтен белдерде, иҗатларында уңышлар теләде. Ноябрь башында «Ак чәчәкләр» кабат районыбызга киләчәк.

Шунысын да әйтеп үтү кирәктер, "Казан егетләре" ансамбле башкаруында фильмда яңгыраган "Ак чәчәкләр" җырының "төп герое" – Мәндәй егете Азат Фәтхетдинов. "Казан медицина институтын тәмамлап Чаллыга эшкә килгәч, аның хезмәт юлында 1 нче балалар больницасында табиб-педиатр, поликлиникада бүлек мөдире, баш табиб, шәһәр сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе, 2 нче шәһәр больницасы баш табибы дигән баскычлар җәйрәп ята. Кайда гына, нинди генә вазифа башкармасын, халык телендә Азат Әдһәмовичның иң беренче чиратта кешелеклек сыйфатлары урын ала", – дип яза фильмның сценарий авторы Айгөл Әхмәтгалиева редакциябезгә юллаган хатында.

**Резеда ШӘРИПОВА**

# БЕЛДЕРҮЛӘР*РЕКЛАМА

618 **ОКНА**

ЕВРО ПЛАСТ®

Вызови замерщика

☎ 7-22-00

Реклама

**ТЕПЛИЦЫ** из поликарбоната

заявки по звонку

• две двери • две форточки
• прочный каркас • поликарбонат 4 мм
• доставка • установка

8*927*966*0*888

www.цмк-экватор.рф

ЭКВАТОР цех металлоконструкций



Реклама. Св-во №3100026915300

Реклама бүлеге телефоны 9–39–80

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Ср 28.10 | Пасмурно, небольшой дождь | +4 | | Пасмурно | +2 |
| Чт 29.10 | Пасмурно, небольшой дождь | +1 | | Пасмурно, снег | +1 |
| Пт 30.10 | Пасмурно, небольшой снег | −1 | | Пасмурно, небольшой снег | −2 |
| Сб 31.10 | Пасмурно, небольшой снег | −5 | | Пасмурно | −4 |

42 **В РЕДАКЦИЮ ГАЗЕТЫ «МАЯК» ТРЕБУЕТСЯ**

специалист по рекламе(по совместительству). Резюме направлять на azmayak@mail.ru. Встреча с кандидатами состоится во вторник 3 ноября в 14.00 часов.

Реклама

*SD-STUDIO*

Разработка мобильных приложений

*создание адаптивных сайтов

*видеоролики и видеопрезентации

*визитные карточки и логотипы

*раскрутка в социальных сетях

Тел. 8-952-032-77-86.

Реклама

## КОТЛЫЙБЫЗ

27 Актүбәдә яшәүче кадерле әти-әниебез **Зөһрә** һәм **Равил Ишмөхәммәтовларны** 65 яшьлек юбилейлары белән кайнар котлыйбыз. Аларның бергә торуларына да 45 ел тулды. Алга таба да шулай туган нигезебезнең җылысын саклап, безне сөендереп, саулык-сәламәтлек белән яшәвегезне телибез. Әти-әни – сез бит безнең тормыш көзгебез, яшәү өлгебез. Сез булганда көннәребез якты, җаннарыбыз тыныч. Барлык кылган яхшылыкларыгыз өчен без зур рәхмәтләр белән башыбызны иябез.

*Гомерегез булсын бәхетле,*
*Бәхетегез булсын гомерле.*
*Безнең өчен җирдә, бар җиһанда.*
*Сез иң газиз һәм иң кадерле,*
*Иртән сызылып аткан алсу таңнар.*
*Чиксез сөенеч алып килсеннәр,*
*Картлык елларыгыз тигезлектә.*
*Бер кайгысыз, имин үтсеннәр.*

**Иң изге теләкләр белән: әниегез Мөнирә, балаларыгыз, оныкларыгыз.**

9 Принимаем заказы на строительство одно и двухэтажных брусовых домов согласно вашего проекта из материалов хвойной породы. Имеются в наличии домокомплекты:

6×9м – 136 тыс.руб.
8×10м – 216 тыс.руб.
9×10м – 238 тыс.руб.
10×12м – 285 тыс.руб.

Доставим своим транспортом.

Адрес: г. Туймазы, ул. Советская, 2 “Г”

Тел.8(34782) 2-00-20; 8-917-483-68-79.

Реклама

## РӘХМӘТ БЕЛДЕРӘБЕЗ

36 Кадерлебез, гаиләбезнең ышанычлы терәге, сөекле тормыш иптәшем, яраткан әтиебез Галиев Мизхәт Гыйлләҗетдин улы вакытсыз арабыздан китеп барды. Авыр югалту ачысын бергә кичерешкән, кара кайгыбызны уртаклашкан, рухи һәм матди ярдәм күрсәткән туганы Рифкатька, сеңлесе Зөһрәгә, Мирсәлимгә, баҗасы Илгизгә, каенише Илкамга, аларның гаиләләренә, әти-әниләребезгә, барлык туганнарга, дусларга, авылдашларга, күршеләргә, 3 нче "Айсылу" балалар бакчасы коллективына, Рәмзия Миргасим кызына, дин әһелләренә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Барыгызга да саулык, озын бәхетле гомер телибез.

**Тормыш иптәше, балалары**

## Ихластан

43 15 октябрь көнне 90 яшем белән котлап, зур бүләкләр күтәреп Шәйдуллин Марсель Зефәр улы җитәкчелегендә Расих Әхәт улы, Мисбах Мусин улы, Фәүзия Инсаф кызы, Гөлнара Нәфигулла кызы килеп кергәч, күңелем тулып, күзләремә яшь килде. Олы кешегә бер җылы сүз, ягымлы караш та җитә, яшәү дәрте арта. Мине олылыклап хөрмәтләүләре өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Үз изгелекләре үзләренә меңе белән кайтсын иде. Эшләгән эшләрендә зур уңышлар, сәламәтлек теләп Актүбә бистәсендә яшәүче тыл ветераны **Җамалетдинов Гыйльметдин.**

59 ***1ноября 2015г. проводится прием специалистов из МедСанЧасти г.Альметьевска по направлению:***

- эндокринология.

проводится прием специалистов из Республиканского онкодиспансера г.Альметьевска по направлениям:

- онкология;
- маммология;
- удаление новообразований.

Тел.7-08-04, 89600803349.

**ЛЕЧЕБНО-ДИАГНОСТИЧЕСКАЯ КЛИНИКА.**

*Лиц.ЛО-16-01-003283 от 28.02.2014 г.ОГРН 1131689001718.*

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ.

НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА *Реклама*

62 ***31 ОКТЯБРЯ И 1 НОЯБРЯ***

***в РГДК г. Азнакаево***

состоится

## Распродажа



фабричных шуб и головных уборов.

Пенсионерам действуют сезонные скидки

Клиенты предъявившие купон участвуют в новогоднем розыгрыше супер призов

Пятигорская фабрика «ЛиС»

Реклама

52 ***31 ОКТЯБРЯ***

***ДК ПГТ.АКТЮБИНСКИЙ***

***ТОЛЬКО ОДИН ДЕНЬ!***

"МЕХОВОЙ СОБЛАЗН"

## ЯРМАРКА

Меховых изделий 2014 -2015 гг.!!!

Спешите!

Шубы. Дублёнки. Пуховики.

Пр-во:Россия.

Действует кредит - 0% первый взнос!*

Подробности узнавайте у продавцов-консультантов или по т.8(3412)51-37-31

Ждём вас с 9.00 до 19.00

кредит предоставляется ОТП банком № лицензии 2766 от 25 мая 2012г.

Реклама

### САТАМ

**МИЛЕК**

45 Продается или меняется на квартиру комната 18 м$^2$ на Ямашева, 6. Тел. 8-917-873-74-54.

**ТРАНСПОРТ**

986 "Нива -212140". Тел. 8-960-071-64-87.

44 Бортовая "Газель", 2006 г. Тел. 8-917-264-82-34.

920 "УАЗ-31519". Тел. 8-917-901-52-17.

**ТӨРЛЕСЕННӘН**

998 Слуховые аппараты (заводские, с гарантией). Тел. 9-50-10, 8-917-268-02-05.

**АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕ, ТЕРЛЕК**

740 Суярдай бройлерлар, үрдәкләр, казлар. Тел. 8-917-936-12-84.

141 Бозаулар. Тел. 8-927-460-21-71.

284 Бозаулар. Тел. (885556) 3-54-18, 8-908-335-59-70.

31 Бер яшьлек кәҗә, бәрәне белән. Тел. 8-917-248-58-23.

34 Жом. Тел. 8-987-272-09-99.

41 Нәселгә сарыклар. Тел.3-42-44.

199 Бычки. Тел. Тел. 8-917-892-28-87.

**ТӨЗЕЛЕШ, ЙОРТ, БАКЧА ӨЧЕН**

871 Навоз, перегной, чернозем, ЖОМ, гравий, песок. Тел. 8-919-648-00-24.

910 Мунча, шилык себерксе. Тел. 8-909-314-98-63.

### САТЫП АЛАМ

569 Ит. Тел. 8-917-346-46-48.

69 Ит. Тел. 8-927-966-55-53.

570 Үгез, сыер, тереләй үлчәм. Тел. 8-927-236-64-61.

686 Үгез, сыер ите. Тел. 8-937-842-10-61.

56 Куплю дорого! Любой лом черных и цветных металлов (холодильники, батареи, стиралки, ванны, электродвигатели, электросварочные аппараты, газовые колонки). Демонтаж. Тел. 8-937-617-26-24, 8-917-880-90-09.

### ХЕЗМӘТ КҮРСӘТӘМ

769 Ком, ПГС, тирес, таш, балчык, торф. Тел. 8-917-262-05-09.

339 Ремонт стиральных машин и СВЧ-микроволновок. Тел. 8-965-610-65-04.

862 Ремонт стиральных машин. Тел. 8-937-774-10-02,8-917-879-20-78.

165 Грузоперевозки. Газель тент. Тел. 8-960-078-40-80.

792 Грузоперевозки. Тел. 8-919-631-37-27.

701 Грузоперевозки. Газель. Тел. 8-917-224-82-30.

481 Срочный ремонт холодильников. Гарантия. Тел. 8-987-005-83-23.

458 Песок, навоз, гравий, щебенка. "КамАЗ"-самосвал. Тел.8-917-394-63-77.

8 Тегү машиналары ремонтлыйм. Тел. 8-917-399-23-51.

10 Чистовая отделка домов. Тел. 8-917-299-46-71.

964 Регулировка, замена уплотнителей, ремонт пластиковых окон. Тел. 8-987-008-37-18.

**57 Оказываем помощь при алкогольной зависимости, табакокурении. Имеется противопоказания. Требуется консультация специалиста. Тел. 8-962-566-56-20.**

### АРЕНДАГА БИРӘМ

908 Помещение в пгт. Актюбинский или продаю. Тел. 8-919-622-19-54.

46 Однакомнатная в Казани. Тел. 8-917-924-23-43.

### ЭШ

38 Расклейщики. Тел. 8-927-467-42-79.

Реклама

50 Азнакай үзәк сырхауханәсе администрациясе, профкомы, ашыгыч ярдәм фельдшеры

**ШАГИЕВ**
**ХӘЛИЛ КӘБИР УЛЫ**

вакытсыз вафат булу сәбәпле, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклашалар.

51 Азнакай үзәк сырхауханәсе администрациясе, профкомы,

**ӘНИСЕ**

вафат булу сәбәпле, поликлиниканың гомумпрактика табибы Дәүләтшина Галия Габделхәй кызының, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклашалар

Гамәлгә куючы – "ТАТМЕДИА" АҖ

www.aznakaevo-rt.ru

Реклама хезмәте телефоны: 8(85592)9–39–80

«МАЯК»

Азнакай муниципаль районы газетасы

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Г.Ә.Кәримова

Редакция адресы: 423330, Азнакай шәһәре, М.Хәсәнов ур., 12
Электрон адрес: azmayak@ mail.ru
Сайт адресы: www.aznakaevo-rt.ru
Телефоннар:
9–43–57- кабул итү бүлмәсе,
9–39–80- реклама бүлеге, факс.
Нәшер итүче: "ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академик ур, 2.

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 16 маенда ПИ № ТУ16-01015 нче танылык белән теркәлде

Газета Түбән Кама шәһәренең «ИПЦ «Гүзәл» ҖЧҖ ндә басылды. Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 18.

Газетаны басарга график буенча 14.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш, фактта - 14.00 сәгатьтә кул куелды.

татмедиа

Тираж - 4237 данә.

ТР матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Редакция фикере һәрвакытта авторлар фикере белән туры килми. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.

**Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

© Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт

Газета чәршәмбе, җомга көннәрендә чыга.
Заказ №5
Газетага язылу индекслары:
физик затлар өчен – 00050;
оешма-предприятиеләр өчен – 00051.

Сату бәясе ирекле.

16+